ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ПОЛЯНКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» октября 2022 года № 8

**Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск районы Прокуратурасының 30.06.2022 ел, № 02-01-16-2022 мәгълүматы нигезендә, гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 21 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 бүлегендәге 2.7.1 пунктының 4 пунктчасы үз көчен югалткан дип санарга;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы авыл җирлеге сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты бинасындагы махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырырга.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе** **Н.И. Александрова**